КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 октябрь г.Казань № 883

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче; 2015 ел, 18 май, 353 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 780 нче; 2017 ел, 14 апрель, 228 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1041 нче; 2019 ел, 26 ноябрь, 1080 нче; 2020 ел, 3 февраль, 69 нчы; 2020 ел, 14 апрель, 281 нче; 2020 ел, 23 июнь, 521 нче; 2020 ел, 4 ноябрь, 991 нче; 2021 ел, 25 февраль, 98 нче; 2021 ел, 20 октябрь, 989 нчы; 2023 ел, 22 июль, 879 нчы; 2023 ел, 10 август, 965 нче; 2023 ел, 25 ноябрь, 1517 нче; 2024 ел, 7 май, 308 нче; 2024 ел, 25 июль, 593 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш

администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 2 пунктындагы «б» пунктчасының алтынчы абзацында татар текстының җөмлә башына «түләнергә тиешле сумма исәпләнү гамәлгә ашырылган көннән соңга калмыйча,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга кушымтаның I бүлегендә:

3 пунктта:

13 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, дәүләт предприятиеләре яки муниципаль предприятиеләр яисә дәүләт учреждениеләре яки муниципаль учреждениеләр тарафыннан төзелгән сервитут билгеләү турындагы килешүләр буенча түләү;»;

түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:

«16) әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән файдалану һәм хайваннар белән эш итү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарының вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә таләпләрне үтәмәгән өчен штрафлар).»;

4 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиешле әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләр, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны ирекле каплаганда түләнә торган түләүләр (махсус саклана торган табигать территорияләрендә әйләнә-тирә мохиткә салынган зыяннан, су объектларына, атмосфера һавасына, туфракларга, җир асты байлыкларына, Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларына, шулай ук аучылык һәм балыкчылык объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә карамаган хайваннар дөньясының башка объектларына салынган зыяннан тыш);»;

6 пунктның 87 – 91 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«87) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (салым органында исәпкә кую срогын бозган өчен штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);

88) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (салым декларациясен (иминият кертемнәре буенча исәп-хисапны) бирү срокларын бозган өчен штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);

89) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (салым контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне бирмәгән (хәбәр итмәгән) өчен штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);

90) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (тамга сугу һәм (яки) мәгълүмат язу буенча таләпләре билгеләнгән, тиешле тамгасы сугылмаган һәм (яки) мәгълүматы язылмаган, шулай ук мондый тамга сугуның һәм (яки) мәгълүмат язуның билгеләнгән тәртибе бозылган товарлар һәм продукция җитештергән яки саткан өчен штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);

91) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (башка штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);»;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 20 – 25 пунктчалар өстәргә:

«20) юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (транспорт чарасы белән идарә итү һәм аны эксплуатацияләү хокукларын законсыз чикләгән өчен штрафлар);

21) юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ

штрафлар (авырлыкны һәм габаритны контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда ачыкланган, авыр йөкле һәм (яки) зур габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар);

22) юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (куркыныч йөкләрне ташу кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар);

23) эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм үз-үзен җайга салучы эшчәнлек өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (ирекле рәвештә сату тыела яки чикләнә торган товарларны (башка әйберләрне) законсыз саткан өчен штрафлар);

24) җәмәгать тәртибенә һәм иҗтимагый иминлеккә яный торган административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (җәмәгатьчелек урыннарында исерек хәлдә йөргән өчен штрафлар);

25) җәмәгать тәртибенә һәм иҗтимагый иминлеккә яный торган административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (башка штрафлар).»;

8 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиешле әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләр, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны ирекле каплаганда түләнә торган түләүләр (махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә әйләнә-тирә мохиткә салынган зыяннан, су объектларына, атмосфера һавасына, туфракларга, җир асты байлыкларына, Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларына, шулай ук аучылык һәм балыкчылык объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә карамаган хайваннар дөньясының башка объектларына салынган зыяннан тыш);»;

17 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән файдалану һәм хайваннар белән эш итү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарының вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (чыгаруларда пычрак матдәләр булу нормативларын яисә тавыш дәрәҗәсе нормативларын арттырып, механик транспорт чараларын файдалануга чыгарган өчен штрафлар);»;

10 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (башка штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);»;

12 пунктта:

5 һәм 6 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (тамга сугу һәм (яки) мәгълүмат язу буенча таләпләре билгеләнгән, тиешле тамгасы сугылмаган һәм (яки) мәгълүматы язылмаган, шулай ук мондый тамга сугуның һәм (яки) мәгълүмат язуның билгеләнгән тәртибе бозылган товарлар һәм продукция җитештергән яки саткан өчен штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);

6) финанслар, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары, кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар чыгару, җитештерү, файдалану һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә административ хокукларны бозган өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (башка штрафлар) (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш);»;

14 пунктча үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин